

**Куркыныч боз билгеләре:**

- Соры, тонык-соры төстә, күзәнәкле
- Су агымы, төшүе урыннарында, күпер астында җир асты сулары чыгу урыннарында, тар каналларда, сазлы ярларда, җылы һәм кайнар сәнәгать һәм коммуналь калдыклар ташлау урыннары янында боз ныклыгы начар булырга мөмкин
- Җылы вакытта боз тизрәк ярлар янында һәм су тиз агымлы урыннарда эри
- Кар астында боз һәрвакыт нечкәрәк, кар сулы урыннарны каплап боз калынлыгы артуны әкренәйтә.
- Боз калынлыгын аяк белән бәрү ысулы белән тикшерү тыела

Куркынычсыз боз - тигез, шома, ачык, калынлыгы 7 сантиметрдан да ким булмаган зәңгәр яки яшел төсмерле. Өстенә чыкканда чатырдамаска тиеш



ТР гражданнар оборонасы
һәм гадәттән тыш хәлләр буенча
укыту-методик үзәгенең
Яр Чаллы шәһәре филиалы

2021



# Боз астына киткән очракта...



**Боз астына киткәндә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре:**

- су астына баш белән төшмәскә;

- авыр әйберләрне салырга – сумка, рюкзак һ.б.;

- паникага бирелмәскә, ярдәм сорарга;

- төшкән урын ягыннан чыгарга;

- боз өстенә ятып кулларны киң куярга;

# Каткан сулыкларда боз астына китү куркынычы бар!



- боз өстенә аякны күтәреп, ярылган урыннан читкә тәгәрәргә;





- үзегезнең эзләрегез буенча 3-4 метр үрмәләп чыгарга.

Судан бозга чыккач та, кире суга китмәс өчен, торып чабарга **ярамый.**

**Гомуми кагыйдәләр:**

- *Ярдан, вакытны югалтмыйча, җылы бинага барып җитәргә;*
- *Барлык киемне салып сыгарга;*
- *Тәнне кызарганчы кызу ышкырга;*
- *Мөмкин булганда коры кием кияргә;*
- *Кайнар чәй эчәргә. Алкоголь эчемлекләр тыела!*
- *112 номеры буенча ашыгыч ярдәм чакырырга.*